**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге Якты Күл торак пунктында гражданнар җыены карары**

14.11.2019 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлегенең Якты Күл торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлегенең Якты Күл авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2020 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:

- торак пункт чикләрендә уртак кулланылыштагы юлларны карап тоту (Ленин ур.);
- зиратка илтүче юлга вак таш җәю;
- паркны төзекләндерү (җәяүлеләр юлына брусчатка җәю; койманы ремонтлау һәм буяу; паркка илтүче җәяүлеләр юлын төзекләндерү).

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Якты Күл авыл җирлеге башлыгы ______________ З. З. Мөхтәров